РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«3» август 2022ел г. Альметьевск № 1673

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Проект документациясен, эшләр башкару проектын һәм инженерлык-топографик планны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 25 маендагы 729 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының 2019 елның 25 мартындагы 147 номерлы карары (үзгәрешләр белән) белән расланган Әлмәт шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә таянып,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1.Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Проект документациясен, эшләр башкару проектын һәм инженерлык-топографик планны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 25 маендагы 729 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 нче кушымтасында:

2.5.1пунктының б) пунктчасын төшереп калдырырга;

2.5.1 пунктының в) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) инженерлык челтәрләрен, объектларны (вакытлыча яки даими койма һәм киртәләр, төзелеш күтәртмәләрен һәм стационар каланчаларны, шәһәр инфраструктурасы элементларын) урнаштыру урыннарын, теләсә нинди материалларны, конструкцияләрне, җайланмаларны 1:500 күләмендә туплауны күрсәтеп, топографик төшерү (DWG формат).»;

2.5.1 пунктының д) пунктчасын төшереп калдырырга;

карарның 1 нче кушымтасындагы 3 бүлекне 3.0.; 3.0.1 пунктлары белән тулылындырырга:

«3.0. Күрсәтелгән хезмәт күрсәтүне гомуми билгеләре белән берләшкән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә, шул исәптән алар алган муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, күрсәтелгән хезмәт күрсәтү тәртибен үз эченә алган муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары.

3.0.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең гомуми билгеләре белән берләшкән категориясенә бәйле түгел. Шуңа бәйле рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүнең гомуми билгеләре белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәт күрсәтү тәртибен үз эченә алган вариантлары, шул исәптән алар мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, билгеләнми».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник»газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов